| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 декабрь г.Бугульма № 1398

**“2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында мәдәниятне үстерү” муниципаль программасын раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга, "Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре" 1992 елның 9 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73 номерлы Федераль закон, "Мәдәният турында" 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60 номерлы Татарстан Республикасы Законнарына таянып:

1. “2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында мәдәниятне үстерү” муниципаль программасын расларга (Кушымта 1).
2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының финанс-бюджет палатасына җирле бюджетны формалаштырганда әлеге программаны тормышка ашыруга финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотарга.
3. Әлеге карарны Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасары Э.Н. Резвановага йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Галиуллин